***Фәтхуллина Айгөл***

# ИСЛАМ – УЛ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

Ислам - галәмнәрнең хуҗасы булган Аллаһ Раббыбызга җаның тәнең белән бирелеп яшәү, ягъни ихлас күңелдән Аңа ышану, Аның алдында түбәнрәк булу, Ул тыйганнардан тыелып, һәрдаим Аны зикер итеп (мактап), фәкать Узеннән генә ярдәм сорап, Ул кушканча күркәм итеп тормыш итү. Ислам – ул Аллаһ Тәгаләгә буйсыну, Аның илчесе булган пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) гә иярү, ул боерган эшләрне үтәү, ул тыйган гамәлләрдән тыелу. Кыямәт көнендә аның шәфагатенә ирешергә мөмкин. Хакыйкый мөселман күңеленең халәте нинди булуга карамастан, Аллаһы Тәгалә һәм Рәсүлебез Мөхәммәд (с.г.в.) кушкан барлык әмерләренә буйсынып яшәргә тиеш.

Ислам – ул туры, хакыйкый юл. Әгәрдә бу хак юлны югалтсак без адашачакбыз. Кеше урманда адашып йоргәндэ, чыгу юлын табуы ничек авыр булса, шулай ук диннән киткән кешеләргә дә икелэтэ авыр булачак. Адәм баласы курыкмый башлый, кунеле телэгэн әйберлэрне генэ эшли, тулаем фани доньяның мәшәкатьләренә чумып бетә. Кылган гамәлләренең нәтиҗәләрен күздә тотмыйча, алар өчен алга таба җавап бирәсен уйламый. Шуның өчен дә ислам диненең - безнең тормыш рәвешебез икәнлеге турында онытырга ярамый. Чөнки ислам – тормышны дөрес күзаллау. Адәм баласы тәнгә, суга, ризыкка ихтыяҗ булган кебек, җанга да дин азыгы кирәк. Дингә булган ихтыяҗ – кеше тормышының аерылгысыз бер өлеше. Дини азык булмаса, яшәүнең мәгънәсе, көче беткән булыр иде. Адәм баласы үзгәрүчән зат. Бер караганда ул яхшы, изге гамәлләр кыла, ә икенче яктан караганда кызыгып тыелганнарга тартыла. Белгәнебезчә, тыелган гамәлләр тышкы кыяфәтләре белән үзенә җәлеп итеп торалар. Әгәр дә кешенең ихтыяр көче, иманы зәгыйфь булса, ул әкренләп шул тыелган эшләргә кереп китә. Шул сәбәпле җәмгыятебездә алкоголизм, наркомания, төрле авырулар, фахишәлек һ.б. яман гамәлләр чәчәк ата. Адэм баласынын ислам динендэ булу бик зур бәлаләрдән котылу чарасы да. Акыл һәм хис – тойгылар һәрвакыт кешенең үзендә булган кимчелекләр белән көрәшә. Бугенге көндә һәрбер кешенең бурычы- доньяда булган явызлыкны юк итү.

Кеше мөселман булса да, булмаса да башкаларның үгет – нәсыйхәтенә мохтаҗ.

Үгет – нәсыйхәтне тыңлаган кеше төрле афәтләрдән азат була. Мөселман кешесе угет – нәсыйхәт нәтиҗәсендә тагын да югарырак дәрәҗәгә ирешә ала. Кешеләрне Аллаһ диненә чакыру һәм өндәү, аларның дингә ышанычын арттыру, шәригать буенча яшәргә өйрәтү – болар барысы да ислам җәмгыятенең аякка басуы.

Әгәр дә адәм баласы ислам диненен шифалы суларын эчмәсә, дингә чакыру үсентесе дә үсмәс һәм тәмле җимешләр дә бирмәс.

Аллаһының илчесе һәм аның сәхабәләре изге гамәлләр кылганнар, аларның һәммәсенең күңелләре яхшылыкка камиллеккә омтылган һәм Аның (Аллаһның) юлыннан тайпылмаганнар.

Әйтеп үткәнемчә, мөселманнар да, мөселман булмаганнар да исламга чакыруга мохтаж. Мөселманнарга үзенең яхшылыкларын арттырып, камиллекнең югарырак баскычына ирешү өчен, ә мөселман булмаганнарга туры, хак юлны табу өчен дингә чакыру, өндәү кирәк.

Аллаһ Тәгалә "Бәкарә" сүрәсенең 257 нче аятендә әйтә: "Аллаһ – иман китергәннәрнең Дусты. Ул ал арны караңгылыктан нурга чыгара. Ә иман китермәгәннәрнең дусты тагут (шайтан). Ул ал арны нурдан караңгылыкка чыгара. Алар – ут (җәһәннәм) әһелләре һәм анда мәңгегә калачак".

Әбү Һөрәйрә разыяллаһү ганһе риваять кылуы буенча, Аллаһның илчесече Мөхәммәт (с.г.в.) әйткән:

"Туры юлга чакыручынын әҗере үзенә – иярүчеләрнең әҗере кадәр ук булачак. Бу аларның үз әҗерләрен әз генә дә кимитмәячәкләр. Адашуга чакыручыга килгәндә, ул үзенә иярүчеләрнеке кадәр ук гөнаһка ия. Бу аларның гөнаһларын әз генә дә киметмәячәк" ди Мөслим. Бу хәдистә дингә өндәүчеләр, бер яктан дәгъват кылучының күркәмлеге турында сөйлиләр, икенче яктан адашудан тыялар.

Дингә чакыру, дингә мәхәббәт тәрбияләү - Аллах Тәгалә барлык белгәннәрен кешеләргә берьюлы сөйләми, ә акрынлап өйрәтә. Дөрес юлга, дингә чакыручы кеше беркайчанда өндәүчеләргә карата түземлеген, сабырлыгын югалтмый. Без сабыр иткән очракта гына эшебез нәтиҗәле була. Сабырлык мөселманнарның төп коралы, чөнки аңа Аллаһ Тәгалә дә таяна. Аллаһ Тәгалә " Бәкарә" сүрәсенең 152 нче аятендә әйтә: "... Дөреслектә, Аллаһ сабыр кылучылар белән." Димәк, Аллаһ Тәгалә сабыр итүчеләрне ярата һәм Үз рәхмәтеннән ташламый. Диндә өндәү, чакыру – ул иң олы, саваплы һәм изге эшләрнең берсе, чөнки Коръәндә язылганча пәйгамбәрләрнең вазыйфасы булган.Аллаһ Тәгалә "Гыймран" сурәсенең 110 нче аятендә әйтә: " Чакыручы ул иң яхшы кеше."Димәк, дингә өндәүче, чакыручы кеше - ул үзенең камильлеген арттырырга теләүче инсан. Ул камильлеккә омтылучы үзенең тормышы турында гына уйлап калмый, ә тирә - юньдәге кешеләр өчен дә борчыла. Аларга Аллаһ Тәгалә рәхмәте белән, Мөхәммәд пәйгамбәребездән үрнәк алып, яхшылыкка, туры, хакыйкый юл белән бара.

Кешенең тормышы һәрвакытта да, үзе теләгәнчә рәхәтлектә, бәхеттә, шатлыкта гына үтми һәм барда яхшы булыр дип гарантия бирә алмый. Чөнки адәм баласы үзенең яшәү дәверендә күп тапкырлар ялгышырга, абынырга, югалып калырга мөмкин. Бер карыйсың ул яхшы гамәлләр кыла, икенче карыйсың зәгыйфь адәми зат хәрамга – тыелган гамәлләргә үреләә. Менә шуның өчен кеше һәрвакытта да кисәтеп, кыек юлга кереп китә башласа, аңа туры хакыйкый юлга маңгай күзен белән генә түгел, ә күңел күзен дә ачарга тиеш. Чөнки күңел күзе

күрмәсә, маңгай күзе генә күреп бетерә алмый. Ә инде вәгазьләгән, аңлаткан чагында Аллаһ Тәгаләнең үзенә һәм пәйгамбәребезнең сөннәтенә игътибар итеп, аннан соң гына фәнни белемнәргә таянып эшләү мәслихәт. Шул очракта гына без, Аллаһ Раббыбыз рәхмәте белән, тиешле нәтиҗәләргә ирешеп, җәмгыятебезне яхшылыкка өндәп, яманлыктан тыеп, коткарып кала алырбыз.

**_АННОТАЦИЯ_**

**_В данной статье Ислам рассматривается как целостный образ жизни, накладывающий на человека ответственность за себя и окружающее его пространство. Важной обязанностью мусульманина является объяснение людям истин Ислама, призыв к благому и предотвращение дурного, соблюдения всех морально-нравственных предписаний исламской религии._**

**_Фатхуллина Айгуль (Казань, Россия) – ассистент кафедры исламского вероучения Российского исламского института._**